Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге составына керүче Свердловец торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елның 27 ноябре № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлегенең Свердловец торак пунктында граждannар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Кармалы авыл җирлеге Свердловец торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире 600 сум күләмендә 2025 елда үзара салым кертергә. Әлеге сумманың 50% күләмендә 2 группа инвалидлар, 80 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнар, 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баланың ата-аналары түли.
2. Алынган акчаларны торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзүгә, ремонтлауга, карап тотуга юнәлтергә (Свердловец бистәсенең Ленин урамындагы бетон юлны ремонтлау).

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кармалы авыл җирлеге башлыгы А.Д. Кубышкин